МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№________________

На №________________от________________

**Руководителям отделов (управлений) образования исполнительных комитетов муниципальных образований Республики Татарстан**

О проведении V республиканских педагогических чтений имени Г.Афзала

**Уважаемые коллеги!**

В целях привлечения учителей к исследовательской работе, приобщения их к духовным ценностям, традициям национальной культуры, выявления творчески работающих учителей Министерство образования и науки Республики Татарстан совместно с Институтом филологии и межкультурной коммуникации Казанского (Приволжского) федерального университета, Управлением образования Исполнительного комитета Актанышского муниципального района, государственным автономным общеобразовательным учреждением «Гуманитарная гимназия-интернат для одаренных детей» 13 мая 2016 года проводит V республиканские педагогические чтения имени Г.Афзала (далее — Чтения).

Для участия в Чтениях приглашаются учителя и воспитатели общеобразовательных организаций Республики Татарстан. Заявку на участие, тезисы выступления, исследовательские материалы необходимо направить в срок до 1 мая 2016 года на электронный адрес venerahaeva@yandex.ru с пометкой «Чтения» и указанием фамилии автора.

Командировочные расходы производятся за счет направляющей стороны.

Место проведения Чтений: ГАОУ «Гуманитарная гимназия-интернат для одаренных детей» с.Актаныш.

Адрес проведения: 423740, Республика Татарстан, с.Актаныш, ул.Аэропортовская, д.3а.

Телефоны для справок: 8(85552) 3 26 05 (секретарь); 89172573988 Хаева-Хаметзянова Венера Хаматнасыховна.

Приложение: на 4 л. в 1 экз.

**Заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр** **Э.Н.Фаттахов**

Л.Р.Зайнуллина, (843) 294 95 10



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Кушымта

**«Гамил Афзал укулары»**
**V республика педагогик укуларын үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми мәгълүмат

1.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы бишенче ел рәттән Казан (Идел буе) Федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Актаныш муниципаль районы «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле гомумбелем учреждениесе белән берлектә күренекле шагыйрь Гамил Афзал истәлегенә багышланган республика укулары үткәрә. Укуда татар халкының әдәбияты һәм мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән Гамил Афзалның тормышы һәм иҗади эшчәнлеге төрле юнәлешләрдә өйрәнелә һәм тикшерелә.

## II. Педагогик укуларның максат һәм бурычлары

Әлеге нигезләмә һәр елны үткәрелә торган «Гамил Афзал укулары» республика педагогик укуларының максатлары һәм бурычларын, аны оештыру, үткәрү тәртибен билгели.

2.1. Гамил Афзал иҗатын өйрәнү һәм аны педагогик җәмәгатьчелеккә таныту.

2.2. Белем бирүне уңышлы рәвештә гамәлгә ашыруга юнәлтелгән фәнни-теоретик һәм укыту-методик материалларны ачыклау һәм куллануга кертү.

2.3.Заман таләпләренә ия булган сыйфатлы белем бирүгә ирешү.

2.4. Укытуның нәтиҗәле технологияләрен һәм ысулларын эзләү; белем бирү процессына инновацияләр кертү.

2.5. Укытучыларның алдынгы эш тәҗрибәсен тарату формаларын камилләштерү аша укытучыларның белемен күтәрү.

2.6. Район, республика педагогик коллективлары, галимнәр белән иҗади элемтәләр кору, нәтиҗәле һөнәри аралашуны оештыру.

## III. Педагогик укуларда катнашучылар

3.1. «Гамил Афзал укулары»нда укытучылар яки белем бирү оешмаларының педагоглар төркеме фәнни-эзләнү эшләре (доклад) белән катнаша. Эшләр мөстәкыйль эшләнгән, мәгълүматлар анализланган һәм аларда авторның үз карашы, фикере чагылырга тиеш.

## IV. Бәйгене оештыручылар

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы.
- Казан Федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты.
- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе.

- Актаныш муниципаль районы «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле гомумбелем учреждениесе.

## V. Укуны оештыру һәм үткәрү тәртибе

5.1. Педагогик укулар ике этапта үткәрелә.

1 этап – әзерлек этабы;

2 этап – төп этап.

**Әзерлек этабы –** гаризаларны кабул итү – 2016 елның 1 маена кадәр. Килгән эшләрне оештыру комитеты составына кергән экспертлар тикшергәннән соң, икенче турда катнашучылар исемлеге 8 нче майда гимназиянең официаль сайтына куела.

**Төп этап.** Икенче турга узган укытучылар 13 май көнне сәгать 9 га Актаныш муниципаль районы «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле гомумбелем учреждениесенә «Гамил Афзал укулары»ның финалына чакырыла. Эшләренең кәгазь варианты чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла.

5.2. Педагогик укулар барышында пленар утырыш, тематик секцияләр эше оештырыла. Педагогик укуларда каралу предметы дип катнашучыларның эш тәҗрибәсенә нигезләнгән фәнни-методик эшкәртмәләр, тикшеренүләр, проектлар санала.

5.3. «Гамил Афзал укулары» кысаларында түбәндәге секцияләр эшләячәк:

***I.Гамил Афзал иҗаты һәм бүгенге әдәбият.***

*- Гамил Афзал иҗатында патриотик тәрбия темасы;*

*- Гамил Афзал иҗатын өйрәнүче галимнәр эшчәнлеге;*

*- Гамил Афзал шигырьләрен мәктәптә укыту тәҗрибәсе һәм аларның тәрбияви әһәмияте;*

***II. Ана телендә белем бирүче мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятын өйрәтүдә заманча педагогик технологияләр һәм укучыларның рухи-әхлакый үсеше проблемалары.***

***III. Башлангыч белем бирүдә заманча технологияләр: традицияләр һәм инновацияләр.***

***IV. Хәзерге заман мәктәбендә эстетик цикл предметларын укыту үзенчәлекләре.***

***V.Чит телләр укытуда метапредметлылык.***

***VI. Мәктәпкәчә белем бирүдә милли тәрбиянең роле.***

***VII. Төгәл фәннәр укытуда Федераль дәүләт белем бирү стандарты.***

***VIII. Татар телендә белем бирүче мәктәпләрдә рус теле һәм әдәбияты дәресләрендә электрон ресурсларын куллану тәҗрибәсе.***

(Оештыру комитеты педагогик укуларда катнашу өчен гаризаларны сайлап алу хокукын үзендә калдыра. Педагогик укуларны әзерләү барышында үзгәрешләр һәм юнәлешләрне берләштерү булырга мөмкин).

5.4. Укуларда катнашу өчен, 2016 елның 1 нче маена кадәр venerahaeva@yandex.ru электрон адресына гариза (заявка), доклад материаллары (10 биткә кадәр) җибәрелергә тиеш.

## VI. Чыгышларның регламенты һәм бәяләү критерийлары

6.1. Казан Идел буе Федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты галимнәре, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе методистлары, Актаныш муниципаль районының югары квалификацион категорияле укытучыларыннан торган экспертлар комиссиясе укытучыларның фәнни эшләренә, чыгышларына түбәндәге критерийлардан чыгып бәя бирә:

- билгеле булган фәнни фактларны куллану;
- сөйләмнең аңлаешлы булуы, кыскалык һәм ачыклык, күргәзмәлелек;
- аудитория белән элемтә;
- оригинальлек, заманчалык һәм чыгыш барышында цифрлы белем бирү ресурсларын нәтиҗәле куллану.

6.2. Секцияләрдә чыгыш ясауга 5-7 минут вакыт бирелә.

6.3. Фәнни-методик эшнең киләсе бизәлеше: формат – А4, бит параметрлары: кырыйлар – өске һәм аскы – 2 см, сул – 3 см, уң – 1,5 см, форматлаштыру бит киңлеге буенча, юл ара интервал –1,5, шрифт зурлыгы – 14. Кырларның контурлары куелмый. Эшнең исеме калын шрифт белән уртага языла. Доклад исеме астында бер интервал аша уртага юл хәрефләре белән авторның фамилиясе, фәнни дәрәҗәсе яки квалификациясе күрсәтелә. Инициаллар фамилия алдында күрсәтелә. Әгәр дә авторлар берничә икән, фамилияләр бер юлга языла. Алдагы юлда кыскартуларсыз оешма яки учреждение атамасы күрсәтелә.

6.4. Оештыручылар эшләрне түбәндәге очракта кире кага ала:

- авторлык буенча шикләр уянса;
- күрсәтелгән вакыттан соңрак тапшырылса;
- РФ һәм ТР кануннарына каршы килсә;
- педагогик укуларның тематикасына туры килмәсә;
- бизәлеш тәртипләрен үтәмичә башкарылган булса;
- логик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион хаталар булса.

## VII. Нәтиҗә чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү

Укытучыларның фәнни эшләренә, чыгышларына эксперт комиссиясе югарыдагы критерийлардан чыгып бәя бирә. Чыгышлар тыңланып беткәннән соң һәр секциядәге экспертлар комиссиясе нәтиҗә чыгара, җиңүчеләрне билгели. Карарлар беркетмәгә теркәлә, үзгәрешсез кабул ителә.

2 нче турда җиңгән укытучыларга да Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дипломнары тапшырыла, катнашучыларга шәһадәтнамә тапшырыла. Уку нәтиҗәләре буенча Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы әзерләнә.

**Белешмәләр өчен адреслар һәм телефоннар:**

Электрон почта адресы: venerahaeva@yandex.ru

423740, Татарстан Республикасы, Актаныш авылы, Аэропортовская ур., 3а

Телефон: 8 (85552) 3 26 05 (сәркатип Чулпан Рәмзиловна)

89172573988 (инновацион эшчәнлек буенча директор урынбасары Венера Нәсиховна Хәева-Хәмитҗанова)

**«Гамил Афзал укулары» V республика педагогик укуларында катнашу өчен гариза**

| | |
|---|---|
| Эшнең темасы | |
| Секция (предмет) | |
| Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулы килеш татар телендә) | |
| Фәнни дәрәҗә,квалификацион категория | |
| Вазыйфа | |
| Оешма (устав буенча татар телендә) (адрес һәм телефон) | |
| Катнашучының телефоны | |
| Чыгыш өчен кирәк булган техник чаралар | |

Оешма җитәкчесенең имзасы
«________» ____________________________________ 2016 ел.

Лист согласования к документу № 4182 от 23.03.2016
Инициатор согласования: Зайнуллина Л. Р. Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 21.03.2016 11:53

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано 21.03.2016 - 18:48 | - |
| 2 | Сайфуллина Ф.С. | | Согласовано 21.03.2016 - 19:03 | - |
| 3 | Мухаметов И.Р. | | Согласовано 21.03.2016 - 20:42 | - |
| 4 | Фаттахов Э.Н. | | Согласовано 21.03.2016 - 22:21 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН